**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылыш XIII утырыш

**КАРАРЫ**

2023 ел «22» февраль № 3 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2022 елда социаль-икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2023 елга бурычлар турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы А.Ә. Шәфигуллинның «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2022 елда социаль-икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2023 елга бурычлар турында» докладын тыңлап, фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы А.Ә. Шәфигуллинның «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2022 елда социаль-икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2023 елга бурычлар турында» отчетын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына 2023 елның 15 мартына кадәр:

-Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы отчетында, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы депутатлары чыгышында әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру чаралары планын эшләргә һәм аны Татарстан Республикасы Ютазы район Советы каравына тәкъдим итәргә;

- аларның максаты булып икътисадны тотрыклы, динамикалы үстерү һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы халкы өчен уңайлы мохит булдыру нигезендә, халыкның тормыш сыйфатын яхшырту торган

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш планнарын уңышлы үтәүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләрен һәм тулаем Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районын комплекслы социаль-икътисадый үстерүгә аерым игътибар бирергә;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләре һәм тулаем Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының салым салына торган базасын булдыру, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен бюджетларына өстәмә финанс чараларын җәлеп итү буенча эшчәнлеген активлаштырырга;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләрендә һәм тулаем Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында яшәүче халыкның тормыш дәрәҗәсен киметүгә юл куймау һәм гражданнарның социаль хезмәтләрне тигез дәрәҗәдә алуларын тәэмин итү чараларын күрергә;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләренең һәм тулаем Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының торак пунктларын төзекләндерү, яшелләндерү, санитар чистарту һәм экологик куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чараларны дәвам итәргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында http:// jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар аны кабул иткән вакыттан үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин